**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

**«31» марта 2023г.** **№ 65**

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 16 гыйнварындагы 13 номерлы «Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан архитектура-шәһәр төзелеше күренешен (капиталь төзелешнең, керү төркемнәренең һәм төзекләндерү объектларының проектлана һәм реконструкцияләнә торган объектларын) килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе норматив хокукый актларында һәм төзүчегә, техник заказчыга капиталь төзелеш объектын төзү проектын гамәлгә ашырганда Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.2 статьясындагы 3-7 өлешләрендә каралган чараларны үтәү өчен кирәкле документларның, белешмәләрнең, материалларның тулы исемлеген раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм кайбер нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 25 декабрендәге 2490 номерлы карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 16 гыйнварындагы 13 номерлы «Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан архитектура-шәһәр төзелеше күренешен (капиталь төзелешнең, керү төркемнәренең һәм төзекләндерү объектларының проектлана һәм реконструкцияләнә торган объектларын) килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (12.11.2018 № 717, 23.01.2020 № 22, 22.04.2020 № 190, 16.06.2021 № 212 карарарлар редакциясендә):

1) Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан архитектура-шәһәр төзелеше күренешен (капиталь төзелешнең, керү төркемнәренең һәм төзекләндерү объектларының проектлана һәм

реконструкцияләнә торган объектларын) килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына:

А) 1.5 пунктының 6 абзацын түбәндәге тәртиптә бәян итәргә:

«- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 25 декабрендәге 2490 номерлы «Россия Федерациясе норматив хокукый актларында һәм төзүчегә, техник заказчыга капиталь төзелеш объектын төзү проектын гамәлгә ашырганда Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.2 статьясындагы 3-7 өлешләрендә каралган чараларны үтәү өчен кирәкле документларның, белешмәләрнең, материалларның тулы исемлеген раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм кайбер нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» карары».

2. Гамәлдәге законнар нигезендә әлеге карарны бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Җитәкче урынбасары – Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты территориаль үсеш бүлеге башлыгы Б.Г. Гайнетдиновка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин